РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТА РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** Буа шәһәре **КАРАР**

05.05.2026 №4-11

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәтне читләштерү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларының үзара эшчәнлеге тәртибе турында» Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2010 елның 18 октябрендәге 10-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлеге милкендәге үзләре арендалый торган мөлкәтне сатып алуга кече һәм урта эшкуарлык субъектларының өстенлекле хокукын гамәлгә ашыру мәсьәләләрен җайга салу максатларында, «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль законга таянып (06.04.2024 ред.), «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон белән (29.12.2025 ред), Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Уставы белән Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәтне читләштерү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларының үзара эшчәнлеге тәртибе турында» Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2010 елның 18 октябрендәге 10-1 номерлы карарына (23.06.2020 № 8-54 ред) киләсе үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1.1.4 Пункт 2 өлештә:

3,4,5 пунктларда «күчемсез» сүзләрен «күчемле һәм күчемсез» сүзләренә алмаштырырга.

түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«6) «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законның 18 статьясындагы 4 өлеше нигезендә расланган кече һәм урта эшкуарлык субъектларына биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән дәүләт мөлкәте яисә муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелмәгән дәүләт яисә муниципаль күчемле мөлкәт.»;

1.2. 2 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) урта предприятиеләр өчен йөз бердән ике йөз илле кешегә кадәр, әгәр урта предприятиеләр өчен хезмәткәрләрнең исемлектәге уртача санының бүтән чик күрсәткече әлеге өлешнең 2.1 һәм 2.2 пунктлары нигезендә билгеләнмәгән булса;»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ рәсми рәвештә бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Буа муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://buinsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә һәм мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль район башлыгы,
Совет рәисе Р.Р.Камартдинов